ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-ЕЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422962, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Чувашский Елтан, ул. Школьная, д.15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ ЯЛТАНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422962, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Чуаш Ялтаны авылы,
Мәктәп ур., 15 йорт

тел. 8(84342) 3-69-33 e-mail: Celt.Ctp@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.06.2023 ел № 16

Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 17 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1.5 пунктында һәм 2.3 пунктында 1-12 пунктчаларын түбәндәге эчтәлекле 1-13 пунктчаларына алмаштырырга:

«1) күчемсез мөлкәт белән эш итүгә ышанычнамәләрдән тыш, ышанычнамә таныклыгы;

2) мирас мөлкәтен мирас мөлкәте исемлеген төзү юлы белән саклау буенча чара күрү;

3) документлар күчермәләренең һәм алардан өзекләрнең дөреслеген раслау;

4) документлардагы имзаның чынлыгын раслау;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында мәгълүмат таныклыгы;

6) гражданның исән булу фактын раслау;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күз күрүе буенча инвалидның үз куллары белән имзаланган имзасы факсимиль рәвештәге имзасы белән бер үк булуын раслау;

8) гражданның билгеле бер урында булу факты таныклыгы;

9) фоторәсемдә күрсәтелгән зат белән гражданның бердәйлеге таныклыгы;

10) документларны тапшыру вакыты таныклыгы;

11) электрон документның кәгазь чыганактагы документка тиңлеген раслау таныклыгы;

12) кәгазь чыганактагы документның электрон документка тиңлеген раслау таныклыгы;

13) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген чагылдыра торган документларның дубликатларын бирү.»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Чуаш Ялтаны
авыл җирлеге башлыгы С.М. Егоров